

# ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘР

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ КИРОВ РАЙОНЫ,»3 НЧЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ ГИМНАЗИЯ»НЕҢ,ЮГАРЫ КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ САДЫЙКОВА ГӨЛСИНӘ СОЛТАН КЫЗЫ**

# Максатлар:

1. Фразеологик әйтелмәләр турында мәгълүмат бирү
2. Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү күнекмәләрен формалаштыру
3. Халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләр аша әхлаклылык тәрбияләү



Эт белән мәче шикелле









- Araларыннан су да үтми.








- Акыллы баш



- Борын салындыру



- Куллары алтын

# Энә төшәр урын юк






**Күчерелмә мәгънәгә ия булган, таркалмый торган сүзтезмә** – фразеологик әйтелмә **дип атала.**

**Фразеологик әйтелмәләр ике яки берничә сүздән тора.**

1. Бакчада бер малай **агач атка атланып** уйный.
2. Безнең бозауның **мөгезе чыкты** инде.
3. **Күз бәйләнгән** килеш уенчыкларны кисеп төшерергә кирәк иде.

1. Җитмәсә, әлеге адәм **агач атка атландырып** китте. (Ф. Х.)
2. Тотасың да үзенчә бер **мөгез чыгара** башлыйсың. (Ә. Ф.)
3. Мин урман авызына кергәндә **күз бәйләнеп** өлгергән иде инде. (Г. Б.)

**Фразеологик әйтелмәләрне башка бер сүз белән алыштыру мөмкин.**

# Мәсәлән:

- Кот очу – курку;
- Авыз еру – көлү;
- Кесәсе калын – бай;
- Карт төлке – хәйләкәр.

Сүз кату

Сүз көрәштерү

Сүзен кисү

Сүз кайтару

Сүзсез калу

Сүзне үлчәп сөйләү

бәхәсләшү

эндәшү

җавап бирү

сүз төгәлләнмичә калу

уйлап сөйләү

эндәшмәү

# Төрле телләрдә фразеологизмнар күп очракта охшаш булалар.

Борын төбендә генә – под носом;

Колагын торгызу – навострить уши;

Бармак аша карау – смотреть сквозь пальцы.

**Күчерелмә мәгънәгә ия булган, таркалмый торган сүзтезмә –** фразеологик әйтелмә **дип атала.**

# Афәрин, булдырдыгыз!

